**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 августындагы 2883 номерлы карары**

# Казан шәһәрендә «Ландыши» сериалын төшерү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны чикләү турында

Казан шәһәрендә «Ландыши» сериалын төшерү чорында куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. ихтыяҗ булган очракта, 2026 елның 31 августында 09:00 сәгатьтән 2026 елның 1 сентябрендә 01:00 сәгатькә кадәр һәм 2026 елның 2 сентябрендә 09:00 сәгатьтән 2026 елның 5 сентябрендә 01:00 сәгатькә кадәр түбәндәге участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны чикләргә:

1.1.1. Батурин урамы, Карл Маркс урамыннан Миславский урамына кадәрге участокта;

1.1.2. Дзержинский урамы, Миславский урамыннан Чернышевский урамына кадәрге участокта;

1.1.3. Миславский урамы, Карл Маркс урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;

1.1.4. Миславский урамындагы 9 номерлы йорт янындагы парковка;

1.1.5. Зилант тыкрыгы;

1.1.6. Кремль дамбасы;

1.1.7. Декабристлар урамы, Кремль дамбасыннан Сибгат Хәким урамына кадәрге участокта;

1.1.8. Сибгат Хәким урамы, Бондаренко урамыннан Декабристлар урамына кадәрге участокта;

1.1.9. Сул як Болак урамы;

1.1.10. Уң як Болак урамы;

1.1.11. Татарстан урамы, Сул як Болак урамыннан Уң як Болак урамына кадәрге участокта;

1.1.12. Астрономия урамы, Сул як Болак урамыннан Кремль урамына кадәрге участокта;

1.1.13. Кремль урамы, Астрономия урамыннан Беренче Май мәйданына кадәрге участокта;

1.1.14. Чернышевский урамы, Кремль урамыннан Профсоюз урамына кадәрге участокта;

1.1.15. Профсоюз урамы, Чернышевский урамыннан Ташаяк урамына кадәрге участокта;

1.1.16. Меңьеллык мәйданы;

1.1.17. Фатыйх Кәрим урамы, Габдулла Тукай урамыннан Каюм Насыйри урамына кадәрге участокта;

1.1.18. Каюм Насыйри урамы;

1.1.19. Иван авышлыгы;

1.1.20. Бауман урамы, Профсоюз урамыннан Батурин урамына кадәрге участокта;

1.2. юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын һәм таранга каршы техниканы урнаштыру өчен җаваплы итеп оештыручыны («Юпитер» ҖЧҖ) билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.3.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары

белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эш оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе (В.В.Жаворонков), Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов) белән берлектә оештыручыга йөк техникасы һәм (яки) таранга каршы блоклар бүлеп бирүдә ярдәм күрсәтергә;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**